**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5090**
**02.08.2021**

Башкарма комитетның «2019-2021 елларга «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 6977 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2019-2021 елларга «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 6977 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 13 ноябрендәге 5995 номерлы, 2021 елның 3 мартындагы 1438 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1 Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы», 03.10, «Су хуҗалыгы» 04.06 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2019 елда - 230,1 мең сум, 2020 елда - 238,8 мең сум, 2021 елда - 3722,9 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2019-2021 елларга «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2020 | 2021 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 230,1 | 238,80 | 3722,9 | 4191,8 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | | - |
| | Барлыгы | 230,1 | 238,80 | 3722,9 | 4191,8»; |

- 3 бүлектә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5. | Гидротехник корылмаларның эксплуатацион ышанычлылыгын арттыру чаралары | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | Гидротехник корылмаларны авариясез эксплуатацияләү дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 230,10 | 238,80 | 2038.80»; |

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «7.1. | Массакүләм ял итү урыннарында җәмәгать коткару постлары булдыру, җиһазландыру һәм эшне оештыру | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен | ел дәвамында | Җәмәгать коткару постлары, пляжлар һәм аларны кирәкле җиһазлар белән җиһазландыру | | | | 100 | | | 1674,1»; |

- 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны ресурслар белән тәэмин итү шәһәр бюджеты акчаларының 4191,9 мең сум күләмен тәшкил итә, шул исәптән:

2019 ел – 230,1 мең сум;

2020 ел – 238,80 мең сум;

2021 ел – 3722,9 мең сум.

Программаны тормышка ашыруга ассигнованиеләр кыскарганда яки артканда, программаны башкаручы чаралар исемлегенә төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр кертә.

Программаны финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм аңа билгеләнгән тәртиптә төгәллекләр кертелергә тиеш».

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов